МИНИСТЕРСТВО СЕЛЬСКОГО ХОЗЯЙСТВА И ПРОДОВОЛЬСТВИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ ҺӘМ АЗЫК-ТӨЛЕК МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

30.09.2015 г.Казань № 228/2-пр

**“2015 – 2016 елларга Татарстан Республикасында җитен комплексын үстерү” ведомство максатчан икътисадый әһәмиятле региональ программасын раслау турында**

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Россия Федерациясе субъектларының авыл хуҗалыгын үстерү буенча икътисадый әһәмиятле региональ программаларына ярдәм итүгә Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына федераль бюджеттан субсидияләр бүлү һәм бирү кагыйдәләрен раслау турында” 2010 елның 17 декабрендәге 1042 номерлы карары нигезендә

**б о е р ы к б и р ә м:**

1. Түбәндәгеләрне расларга:

1.1. “2015 – 2016 елларга Татарстан Республикасында җитен комплексын үстерү” ведомство максатчан икътисадый әһәмиятле региональ программасын (алга таба – Программа) 1 нче кушымта нигезендә;

1.2. Программаны гамәлгә ашыруда катнашучы авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә 2015 елда субсидияләр бирү тәртибен 2 нче кушымта нигезендә;

1.3. Программаны гамәлгә ашыруда катнашучы авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә субсидияләр бирү турында килешүне 3 нче кушымта нигезендә;

1.4. Программаны гамәлгә ашыруда катнашучы авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә, крестьян (фермер) хуҗалыкларына, индивидуаль эшкуарларга федераль бюджет акчалары исәбеннән бирелергә тиешле субсидияләр турында исәп-хисап белешмәнең формасын 4 нче кушымта нигезендә;

1.5. Программаны гамәлгә ашыруда катнашучы авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә, крестьян (фермер) хуҗалыкларына, индивидуаль эшкуарларга Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән бирелергә тиешле субсидияләр турында исәп-хисап белешмәнең формасын 5 нче кушымта нигезендә.

2. Тапшырыла торган документларның дөреслеге, бюджет акчаларының максатчан кулланылуы өчен җаваплылыкны субсидияләрне алучыларга, Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексы оешмаларының җитәкчеләренә һәм баш бухгалтерларына йөкләргә.

3. Бюджет алучы тарафыннан тапшырыла торган документларның дөреслеген тикшерүне һәм раслауны Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Татарстан Республикасы муниципаль районнарында Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәләре башлыкларына йөкләргә.

4. Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының (алга таба – Министрлык) игенчелек тармакларын үстерү бүлеге башлыгы В.Л. Новичковка, Министрлыкның инвестицияләр сәясәте һәм максатчан программалар бүлеге башлыгы И.Ш. Гафуровка һәм Министрлыкның агросәнәгать комплексын инженерлык-техник яктан тәэмин итү бүлеге башлыгы Р.Н. Булатовка авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләрдән, крестьян (фермер) хуҗалыкларыннан, индивидуаль эшкуарлардан федераль бюджеттан һәм Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр алу өчен тапшырыла торган документларын кабул итүне тәэмин итәргә.

5. Финанс бүлеге башлыгы М.А. Мәхмүтовка авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә, крестьян (фермер) хуҗалыкларына, индивидуаль эшкуарларга субсидияләрне үз вакытында бирүне тәэмин итәргә.

6. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны министрның беренче урынбасары Н.Л. Титовка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
урынбасары – министр М.Г. Әхмәтов

2015 елның 30 сентябрендәге 228-2/пр номерлы
ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы боерыгына
1 нче кушымта

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ ҺӘМ АЗЫК-ТӨЛЕК МИНИСТРЛЫГЫ

# “2015 – 2016 ЕЛЛАРГА ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА ҖИТЕН КОМПЛЕКСЫН ҮСТЕРҮ”

# ВЕДОМСТВО МАКСАТЧАН ИКЪТИСАДЫЙ ӘҺӘМИЯТЛЕ РЕГИОНАЛЬ ПРОГРАММАСЫ

Казан 2015

## Эчтәлек

1. “2014 – 2016 елларга Татарстан Республикасында җитен комплексын үстерү” ведомство максатчан икътисадый әһәмиятле региональ программасының паспорты.........................................................3
2. Хәл ителеше программада карала торган проблемаларга характеристика .5
3. Җитен тармагының хәзерге торышына анализ ..................................6
4. Программаның максатлары һәм бурычлары.......................................8
5. Программадан көтелә торган нәтиҗәләр һәм максат индикаторлары.......8
6. Программа чараларының исемлеге һәм тасвирламасы............................9
7. Программаны тормышка ашыру сроклары.........................................10
8. Программаны тормышка ашырганнан соң ирешеләчәк социаль, икътисадый нәтиҗәләргә тасвирлама, максатка ирешүдә программаның өлешенә гомуми бәя бирү..........................................................10
9. Бюджет акчаларын нәтиҗәле сарыф итүгә бәя бирү..............................11
10. Программаның ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү..................12
11. Программаны тормышка ашыруга идарә итү системасына тасвирлама...13
12. Программаны тормышка ашыруның куркынычлы якларына бәя бирү…14

**1. “2015 – 2016 елларга Татарстан Республикасында җитен комплексын үстерү” ведомство максатчан икътисадый әһәмиятле региональ программасының паспорты**

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | “2015 – 2016 елларга Татарстан Республикасында җитен комплексын үстерү” ведомство максатчан икътисадый әһәмиятле региональ программасы |
| Программаны эшләү өчен нигез | 2013 – 2020 елларга авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чималы һәм азык-төлек базарларын җайга салу буенча дәүләт программасы (РФ Хөкүмәтенең 2012 елның 14 июлендәге 717 номерлы карары белән расланган)<br>“2013 – 2020 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чималы һәм азык-төлек базарларын җайга салу” дәүләт программасы (ТР Министрлар Кабинетының 2013 елның 8 апрелендәге 235 номерлы карары белән расланган) |
| Программаның заказчысы | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы |
| Программаны төп эшләүчеләр | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы |
| Программаның максаты | Үзебезнең җитен продукциясенең чимал базасын булдыру һәм җитештерүне арттыру |
| Төп бурычлар | 1 бурыч. Җитен сүсен тулаем җыюны арттыру.<br>2 бурыч. Озын сүсле җитен орлыкларын тулаем җыюны арттыру.<br>3 бурыч. Җитен сүсен эшләп чыгаруны арттыру. |
| Программада катнашучылар | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы, Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексының авыл хуҗалыгы предприятиеләре. |
| Программаның төп чаралары | 1. Җитенне беренчел эшкәртү объектларын төзүгә, шул исәптән аларны реконструкцияләүгә, техник яктан яңадан җиһазлауга һәм модернизацияләүгә капитал чыгымнары.<br>2. Җитен, киндер һәм башка сүсле культураларны сүскә күчергәндә Россия Федерациясенең эчке базарында сатучы товар җитештерүчеләргә җитен (озын сүсле җитен яки май җитене), киндер һәм башка сүсле культураларны җитештерүгә киткән чыгымнарының бер өлешен субсидияләү. |
| Программаны тормышка ашыруның сроклары һәм | 2015 – 2016 еллар |

| | |
|---|---|
| баскычлары | |
| Программаны үтәүчеләр | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы, Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексының авыл хуҗалыгы предприятиеләре. |
| Финанслау күләмнәре һәм чыганаклары | Барлыгы 185,0 млн. сум, шул исәптән:<br>региональ бюджеттан – 44,0 млн. сум<br>бюджеттан тыш чыганаклардан – 141,0 млн. сум<br><br>2015 ел – 87,0 млн. сум, шул исәптән:<br>региональ бюджеттан – 20,0 млн. сум<br>бюджеттан тыш чыганаклардан – 67,0 млн. сум<br><br>2016 ел – 96,0 млн. сум, шул исәптән:<br>региональ бюджеттан – 22,0 млн. сум<br>бюджеттан тыш чыганаклардан – 74,0 млн. сум |
| Максат индикаторы һәм программаның күрсәткечләре (2013 елга карата 2016 ел) | 1. Җитен сүсен җыюны 1,14 мең тоннага арттыру;<br>2. Озын сүсле җитен орлыкларын җыюны 0,07 мең тоннага арттыру;<br>3. Озын сүсле җитен уңышын 0,6 ц/га арттыру;<br>4. Утырту мәйданын 700 га арттыру;<br>5. Җитен сүсен эшләп чыгаруны 990 тоннага арттыру |
| Программаны тормышка ашырудан көтелә торган нәтиҗәләр<br>(2016 елда) | 1. Җитен сүсен тулаем җыю 1,8 мең тоннага кадәр;<br>2. Озын сүсле җитен орлыкларын тулаем җыю 0,12 мең тоннага кадәр;<br>3. Озын сүсле җитен уңышы 13,8 ц/га;<br>4.Чәчү мәйданы 1,2 мең га кадәр;<br>5. Җитен сүсен эшләп чыгару 1,62 мең тоннага кадәр. |
| Идарә итү һәм тикшереп тору системасы | Программаны тормышка ашыру өчен Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының игенчелек тармакларын үстерү бүлеге җаваплы була. |

## 2. Хәл ителеше программада карала торган проблемаларга характеристика

“2015 – 2016 елларга Татарстан Республикасында җитен комплексын үстерү” ведомство максатчан икътисадый әһәмиятле региональ программасы җитен үстерү тармагын тотрыклы үстерү өчен нигез булырга тиеш, бу исә агросәнәгать комплексын үстерүнең өстенлекле максатларына ирешүдә бер баскыч булып тора.

Программа 2013 – 2020 елларга авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чималы һәм азык-төлек базарларын җайга салу буенча дәүләт программасы кысаларында эшләнде.

Илнең җитен чәчүче регионнарында тулаем продуктның зур өлешен туку һәм җиңел сәнәгать продукциясе тәшкил итә. Илебездә һәм дөньяда табигый сүсләрдән тукылган тукымаларга, аеруча уникаль кулланылыш үзлекләренә ия булганга күрә, җитенгә сорауның даими арта баруы туку сәнәгатен үстерүне һәм яңартуны тизләтүне таләп итә. Бу исә, үз чиратында, җитен сүсен җитештерүне арттырырга этәргеч бирәчәк. Россиянең җитен комплексын үстерүдә җитди ихтыяҗ туа, бу ил икътисадының туку, химия, азык, фармацевтика, медицина, оборона тармаклары өчен үзебезнең ышанычлы чимал базасын булдыруга этәрәчәк.

Җитен комплексын тотрыклы үстерү стратегиясе, җитештерү арту тизлегенең артуы аның эчке кулланылыш күләмнәре һәрдаим артып торганда җитен продукциясен өстәмә арттыру, шулай ук импортны алмаштыру (мамык чималы импортын киметү) хисабына тәэмин ителә ала.

Җитен комплексын тотрыклы үстерү өчен булган мөмкинлекләрне уңышлы тормышка ашыру юлындагы төп киртә - тармакның техник тәэминаты начар булу.

Җитен комплексын үстерүнең төп факторы производствога инновацион технологияләрне кертүдән гыйбарәт. Заманча технологияләрне куллану продукциянең сыйфатын дөньяви стандартлар дәрәҗәсендә булуын, җитеннән яңа төр, аеруча икътисадның башка тармакларында ихтыяҗ булган продукцияләр эшләп чыгару мөмкинлеген тәэмин итә. Бу юнәлештә заманча фәнни тикшеренүләрнең булмавы җитен комплексын инновацияле үстерү процессын тоткарлый.

Шул рәвешле җитен җитештерүне үстерүдә “йомык түгәрәк” барлыкка килә: үсеш өчен ресурсларның җитешмәве технологик артта калуга сәбәп була, шуңа күрә продукциянең сыйфаты да түбән, җитештерүдә чыгымнар да зур, импортка караганда конкуренциядә сәләтлелеге дә түбән була. Мондый шартларда тармакның инвестицияләр җәлеп итүчәнлеге шулай ук түбән дәрәҗәдә кала, бу аны үстерү өчен ресурслар җәлеп итү мөмкинлеген чикли.

“2015 – 2016 елларга Татарстан Республикасында җитен комплексын үстерү” программасы күрсәтелгән проблемаларны хәл итү өчен эшләнде дә.

## 3. Җитен тармагының хәзерге торышына анализ

Озын сүсле җитен – Россиядә туку сәнәгате өчен чимал бирә торган бердәнбер авыл хуҗалыгы культурасы. Ул зур агротехник әһәмияткә ия, тулаем чәчү әйләнешенең продуктивлыгын арттыра, күп кенә авыл хуҗалыгы культураларының кыйммәтле башлангычы булып тора. Озын сүсле җитеннең биологик үзлекләре аның туфрак-климат шартларына карата үзенчәлекле таләпләр куя, әйтик, уңай температуралар суммасына, явым-төшем күләменә, туфрак тибына. Озын сүсле җитеннең вегитация чоры 70 көннән 90 көнгә кадәр тәшкил итә, ә 18 С тан югарырак булган температуралар суммасы 700 дән алып 1227 С тәшкил итәргә тиеш. Шушы параметрлар аның Россия террриториясендә үсүен билгели дә.

Озын сүсле җитен күп көч таләп итә торган игенчелек культурасы булып тора, аның өчен җир эшкәртү өчен югары дәрәҗәдәге матди-техник чыгымнар сорала, алар исә бөртекле культураларны үстерүгә караганда 3-5 тапкыр күбрәк, шул ук вакытта ресурсларның гомуми исәбеннән 1/3 кадәр өлешен уңыш алганчы бер ел алдан сарыф итәргә кирәк һәм ягулык материалларына, минераль ашламаларга һәм үсемлекләрне яклауның химик чараларына ел саен бәяләрнең артуын исәпкә алсак, аны җитештерүнең үзкыйммәте дә үсә.

Озын сүсле җитеннең авыл хуҗалыгы предприятиеләре тарафыннан кырларда үстерелүе игенчелек культураларының тулаем күтәрелешенә, чәчү әйләнешендәге барлык культураларның уңышын арттыруга ярдәм итә. Аерым алганда, турыдан-туры озын сүсле җитеннән соң соң чәчелә торган сабан культуралары күп уңыш бирәләр. Бу озын сүсле җитеннән соң җирнең чүп үләннәреннән арынуы һәм туклыклы матдәләргә баюы белән аңлатыла.

Хәзерге вакытта озын сүсле җитенне үстерүдәге төп проблемаларның берсе техника кытлыгыннан гыйбарәт. Чәчү һәм уңыш җыю вакытының бозылуы авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә уңыш ягыннан шактый зыян китерәләр. Озын сүсле җитенне җыеп алгандагы төп югалтулар башка авыл хуҗалыгы культураларына караганда күбрәк. Өстәмә рәвештә җитен җыю техникасын сатып алу ихтыяҗы бар.

**2013 елда**
**Татарстан Республикасында җитен тармагы күрсәткечләре**

**1 нче таблица**

| Индикатор исеме | Исәп берәмлеге | 2013 ел |
|---|---|---|
| 1. Җитен сүсен тулаем җыю | мең тонна | 0,66 |
| 2. Озын сүсле җитен орлыкларын тулаем җыю | мең тонна | 0,05 |
| 3. Озын сүсле җитен уңдырышлылыгы | ц/га | 13,2 |
| 4. Чәчү мәйданы | гектар | 500 |
| 5. Җитен сүсен эшләп чыгару | тонна | 630 |

**2014 елның 1 гыйнварына**
**агросәнәгать комплексының җитен тармагы предприятнеләрендә озын сүсле җитенне үстерү һәм җыеп алу буенча махсус авыл хуҗалыгы машиналарының, технологик җиһазларның таушалу дәрәҗәсенә анализ**

**2 нче таблица**

| Җитен орлыкчылыгы станцияләре | | Җитен заводлары | |
|---|---|---|---|
| Яше | Гомуми йомгакка карата процентларда җиһазландыру | Яше | Гомуми йомгакка карата процентларда җиһазландыру |
| 10 елга кадәр | - | 10 елга кадәр | 100% |
| 10 елдан алып 20 елга кадәр | - | 10 елдан алып 20 елга кадәр | |
| 20 елдан күбрәк | - | 20 елдан күбрәк | |

**2014 елның 1 гыйнварына**
**җитен чәчә торган хуҗалыкларда озын сүсле җитенне үстерү һәм җыеп алу буенча махсус авыл хуҗалыгы машиналарының таушалу дәрәҗәсенә анализ**

**3 нче таблица**

| Техниканың исеме | 8 елдан артык кулланыла торган техниканың булуы, гомуми исәпкә караганда процентларда |
|---|---|
| Катнаш СКЛ-3,6 чәчкече | 100 |
| Җитен җыю комбайны | 70 |
| Җитенне йолку машинасы | 50 |
| Җитен тасмаларын чорнагыч | 70 |
| Рулонга тыгызлый торган җайланма | 50 |
| Тарагыч-җыйгыч машина | 100 |
| Җитен тасмаларын әйләндерү машинасы | юк |
| Порцияләр ясау машинасы | юк |
| Рулон төягеч | 50 |
| Җитен орлыгы көшелен киптерү машинасы | юк |
| Җитен орлыгы көшелен сугу машинасы | юк |
| Орлык чистарту машинасы | юк |

## 4. Программаның максатлары һәм бурычлары

*Программаның максаты – үзебезнең җитен продукциясенең чимал базасын булдыру һәм аны җитештерүне арттыру.*

Куелган максатка ирешү киләчәктә тулы, нәтиҗәле үсә торган җитен комплексын булдыру өчен ышанычлы нигез булачак.

Программа максатларына ирешү өчен түбәндәге бурычларны хәл итәргә кирәк:

җитен сүсен җыюны 1,14 мең тоннага арттыру;

озын сүсле җитен орлыкларын җыюны 0,07 мең тоннага арттыру;

озын сүсле җитен уцышын 0,6 ц/га арттыру;

утырту мәйданын 700 гектарга арттыру;

җитен сүсен эшләп чыгаруны 990 тоннага арттыру.

## 5. Программадан көтелә торган нәтиҗәләр һәм максат индикаторлары

Программа максатларына чыгарыла торган продукциянең физик күләмнәре артканда һәм технологик чылбырның барлык стадияләрендә җитештерү нәтиҗәлелеге күтәрелгәндә ирешеп була.

Программаны тормышка ашыру нәтиҗәсе сан күрсәткечләре белән билгеләнә, алар объективлык, дөреслек, ачыклык, нисбәтлек критерийларына җавап бирәләр.

Программаның еллар буенча максат индикаторлары – 4 нче таблиңада, программаның максат индикаторлары 5 нче таблицада бирелгән.

**4 нче таблица**

| Индикатор исеме | Исәп берәмлеге | План чоры – индикаторлар (күрсәткечләр) | | |
|---|---|---|---|---|
| | | 2014 ел | 2015 ел | 2016 ел |
| 1. Җитен сүсен тулаем җыю | мең тонна | 1,3 | 1,5 | 1,8 |
| 2. Озын сүсле җитен орлыкларын тулаем җыю | мең тонна | 0,09 | 0,1 | 0,12 |
| 3. Озын сүсле җитен уңдырышлылыгы | ц/га | 13,5 | 13,6 | 13,8 |
| 4. Чәчү мәйданы | гектар | 860 | 1000 | 1200 |
| 5. Җитен сүсен эшләп чыгару | тонна | 1109 | 1320 | 1620 |

### Программаны тормышка ашыру чорына җитен комплексы продукциясен җитештерүнең арту темплары

**5 нче таблица**

| Индикаторлар исеме | Җитен җитештерү продукциясен җитештерүнең арту темплары, узган елга карата процентларда | | |
|---|---|---|---|
| | 2014 ел | 2015 ел | 2016 ел |
| 1. Җитен сүсен тулаем җыю | 197 | 115 | 120 |
| 2. Озын сүсле җитен орлыкларын тулаем җыю | 180 | 111 | 120 |
| 3. Озын сүсле җитен уңдырышлылыгы | 102 | 101 | 101 |
| 4. Чәчү мәйданы | 172 | 116 | 120 |

| 5. Җитен сүсен эшләп чыгару | 174 | 120 | 123 |
|---|---|---|---|

**Моңа кадәрге 2 елның уртача күрсәткечләренә карата программаны тормышка ашыруның еллар буенча (табигый зурлыкларда) җнтештерү арту**

**6 нчы таблица**

| Индикатор исеме | Исәп берәмлеге | 2 ел өчен уртача күрсәткечләр (2012 - 2013 еллар) | Арту | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | 2 ел өчен уртача күрсәткечләргә карата 2014 ел | 2 ел өчен уртача күрсәткечләргә карата 2015 ел | 2 ел өчен уртача күрсәткечләргә карата 2016 ел |
| 1. Җитен сүсен тулаем җыю | мең тонна | 0,88 | 0,42 | 0,62 | 0,92 |
| 2. Озын сүсле җитен орлыкларын тулаем җыю | мең тонна | 0,07 | 0,02 | 0,03 | 0,05 |
| 3. Озын сүсле җитен уңдырышлылыгы | ц/га | 11,9 | 1,3 | 1,6 | 1,9 |
| 4. Чәчү мәйданы | гектар | 740 | 120 | 260 | 460 |
| 5. Җитен сүсен эшләп чыгару | тонна | 780 | 320 | 540 | 840 |

**Моңа кадәрге 2 елның уртача күрсәткечләренә карата программаны тормышка ашыруның еллар буенча процентларда җнтештерү арту**

**7 нче таблица**

| Индикатор исеме | Исәп берәмлеге | 2 ел өчен уртача күрсәткечләр (2012 -2013 еллар) | Арту | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | 2 ел өчен уртача күрсәткечләргә карата 2014 ел, % | 2 ел өчен уртача күрсәткечләргә карата 2014 ел, % | 2 ел өчен уртача күрсәткечләргә карата 2014 ел, % |
| 1. Җитен сүсен тулаем җыю | мең тонна | 0,88 | 125 | 159 | 182 |
| 2. Озын сүсле җитен орлыкларын тулаем җыю | мең тонна | 0,07 | 128 | 142 | 171 |
| 3. Озын сүсле җитен уңдырышлылыгы | ц/га | 11,9 | 113 | 114 | 116 |
| 4. Чәчү мәйданы | гектар | 740 | 116 | 135 | 162 |
| 5. Җитен сүсен эшләп чыгару | тонна | 780 | 320 | 540 | 840 |

## 6. Программа чараларының исемлеге һәм тасвирламасы

Татарстан Республикасында озын сүсле җитенне чәчү, үстерү һәм җыю белән җитен чәчү хуҗалыклары шөгыльләнә. Озын сүсле җитенне үстерү производствосы продукциясе сүскә күчергәндә җитен трестыннан, җитен саламыннан һәм озын сүсле җитеннең орлыкларыннан гыйбарәт.

Житен үстерү зур чыгымнар таләп итә. Бу туфракны махсуслаштырылган техника белән эшкәртүгә, аерым төр ашламалар һәм гирбицидлар куллануга бәйле. Житенне җыю өчен шулай ук махсуслаштырылган кыйммәтле комбайннар кулланыла.

Житен җитештерүгә чыгымнарның бер өлешен субсидияләү өчен сүскә күчереп житенне сатучы товар җитештерүчеләргә Татарстан Республикасы бюджетыннан һәм бюджеттан тыш чыганаклардан 37,5 млн. сум кирәк.

Татарстан Республикасында җитен чималын эшкәртү җитен заводларында башкарыла. Әлеге предприятиедә эшләп чыгарыла торган озын сүс туку сәнәгате предприятиеләренә һәм кыска сүс төзелеш тармагы предприятиеләренә җибәрелә. Житен заводларын реконструкцияләү, техник һәм технологик яңадан җиһазлау гамәлләре әлеге предприятиедә җитен чималын югары сыйфатлы, европаның сыйфат стандартларына җавап бирә торган озын сүсне, шулай ук җитеннән продукциянең, аеруча хәзерге вакытта соралган яңа ассортиментын чыгарып тирән эшкәртүне тәэмин итәргә мөмкинлек бирәчәк.

Житен сүсен эшләп чыгаруны арттыру бурычлары Татарстан Республикасы бюджеты һәм бюджеттан тыш чыганаклар акчалары исәбеннән субсидияләр бирү юлы белән хәл ителәчәк.

Реконструкцияләү, техник һәм технологик яңадан җиһазлау гамәлләренең гомуми бәясе – 261,5 млн. сум.

## 7. Программаны тормышка ашыру сроклары

Программа чараларын үтәү ике елга – 2015-2016 елларга каралган. Житен тармагын төзү, реконструкцияләү, техник һәм технологик яңадан җиһазлау һәм модернизацияләү гамәлләрен башкару проект документларында каралган.

Орлыклар һәм минераль ашламалар сатып алу гамәлләре, озын сүсле җитенне үстерү эшләре сезонлы булып тора, алар иң уңай агротехник срокларда башкарылачак.

Программа 2015-2016 еллар чорында гамәлгә ашырылачак.

**Программа чараларын гамәлгә ашыру графигы**

| № т/б | Программа бүлекләре, чаралар | Үтәлеше өчен җаваплы | Үтәү сроклары | Эшләр күләме | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Житен комплексы чыгымнары | Министрлык | 2015-2016 еллар. | 183 млн. сум | |

## 8. Программаны тормышка ашырганнан соң ирешеләчәк социаль, икътисадый нәтиҗәләргә тасвирлама, максатка ирешүдә программаның өлешеиә гомуми бәя бирү

Житен җитештерү тармагын үстерү нәтиҗәле технологик чылбыр булдыруны күздә тота: чимал җитештерү – беренче тапкыр эшкәртү - әзер продукция җитештерү. Бу сыйфатлы озын сүс, азыкка куллана торган һәм

техник җитен маен һәм туку, азык, медицина, химия, фармацевтика, илкүләм икътисадның төзелеш тармагына караган соралган башка төр яңа продукция чыгаруны тәэмин итәчәк.

Шулай итеп, җитен комплексын тотрыклы үстерү икътисадның янәшә тармакларын ышанычлы чимал базасын булдыру өлешендә үстерүгә уңай йогынты ясаячак.

Моннан тыш, программаны тормышка ашыру яңа эш урыннары булдыруны тәэмин итәчәк, тармакка югары квалификацияле белгечләр җәлеп итәргә ярдәм итәчәк, бу авыл хуҗалыгы производствосында аеруча мөһим. Авыл хуҗалыгы производствосының һәм җитен чималын беренче тапкыр эшкәртүнең уңышлы үсүе барлык дәрәҗәдәге бюджетларга салым күчерүләрдән финанс чаралары керүне арттырачак.

Программаны тормышка ашыру үзебезнең үсемлекчелек продукциясенең конкуренциягә сәләтлелеген арттырырга ярдәм итәчәк, җитен житештерүне тотрыклы үстерү һәм җитен сүсен җитештерү күләмнәрен арттыру өчен шартлар һәм алшартлар тудырачак.

## 9. Бюджет акчаларын нәтиҗәле сарыф итүгә бәя бирү

Программаның максат индикаторлары динамикасын анализлау, финанслау тулы күләмендә башкарылган очракта, җитештерү күләмнәренең шактый артуын тәэмин итәчәген күрсәтә.

Күрсәтелгән индикаторларның һәм программаны тормышка ашыруны финанслау күләмнәренең еллар буенча динамикасы 8 нче һәм 9 нчы таблицаларда китерелә:

**Программаны тормышка ашыруның еллар буенча индикаторлар динамикасы**

**8 нче таблица**

| Күрсәткечләр | 2014 ел | 2015 ел | 2016 ел | 3 елга барлыгы: |
|---|---|---|---|---|
| 1. Җитен сүсен тулаем җыю, мең тонна | 1,3 | 1,5 | 1,8 | 4,6 |
| 2. Озын сүсле җитен орлыкларын тулаем җыю, мең тонна | 0,09 | 0,1 | 0,12 | 0,31 |
| 3. Озын сүсле җитен уңдырышлылыгы, ц/га | 13,5 | 13,6 | 13,8 | - |
| 4. Чәчү мәйданы, гектар | 860 | 1000 | 1200 | 3060 |
| 5. Җитен заводларында җитен сүсен эшләп чыгару, тонна | 1100 | 1320 | 1620 | 4040 |
| 6. Җитен сүсен сатудан алган табыш млн. сум | 44,4 | 52,8 | 64,8 | 162,0 |
| 7. Эшләп чыгаруның еллык артуы | 19,2 | 8,4 | 12,0 | 39,6 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| млн. сум | | | | |
| 8. Эшләп чыгаруның процентларда артуы | 176 | 119 | 122 | - |
| 9. Эш урыннары булдыру | 5 | 10 | 15 | 30 |

Программаны тормышка ашыру тискәре экологик нәтиҗәләргә китерми, ул игенчелек культураларын яхшырту буенча культура – техник гамәлләр башкару юлы белән төбәкнең табигый байлыкларын торгызуга һәм саклап калуга ярдәм итәчәк.

**Тормышка ашыруны еллар буенча финанслау күләмнәренең нәтиҗәлелеге динамикасы**

**9 нчы таблица**

| Күрсәткечләр | 2014 ел | 2015 ел | 2016 ел | 3 елга барлыгы: |
|---|---|---|---|---|
| Финанслау күләме, млн. сум | 116,0 | 87,0 | 96,0 | 299,0 |
| 1. Җитен сүсен тулаем җыю, мең тонна | 1,3 | 1,5 | 1,8 | 4,6 |
| 2. Озын сүсле җитен орлыкларын тулаем җыю, мең тонна | 0,09 | 0,1 | 0,12 | 0,31 |
| 3. Озын сүсле җитен уңдырышлылыгы, ц/га | 13,5 | 13,6 | 13,8 | - |
| 4. Чәчү мәйданы, гектар | 860 | 1000 | 1200 | 3060 |
| 5. Җитен заводларында җитен сүсен эшләп чыгару, тонна | 1100 | 1320 | 1620 | 4040 |
| 6. Җитен сүсен сатудан алган табыш млн. сум | 44,4 | 52,8 | 64,8 | 162,0 |
| 7. Нәтиҗәлелек күрсәткечләре, процентларда | 16,5 | 9,6 | 12,5 | 38,6 |

## 10. Прөграмманың ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү.

Программаны финанслау Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән һәм бюджеттан тыш чыганакларның акчаларын җәлеп итү хисабына башкарылачак.

Программа буенча планлаштырылган гамәлләрне тормышка ашыру өчен кирәкле акчаларның күләме орлык заводларын технологик җиһазлауга капитал салуларга экспертлар бәяләрен исәпкә алып исәпләнә.

Программа гамәлләрен финанслау күләмнәре һәм чыганаклары буенча исәп-хисаплар һәм башлангыч күрсәткечләр 10 нчы таблицада китерелгән.

**Программа гамәлләрен финанслауда гомуми ихтыяҗ һәм анық чыганаклары, млн. сум.**

**10 нчы таблица**

| Гамәлләр | Чыганак | 2014 ел | 2015 ел | 2016 ел | 2014-2016 елларга барлыгы |
|---|---|---|---|---|---|
| Җитен комплексына чыгымнар | Региональ бюджет | 46 | 20 | 22 | 88 |
| | Бюджеттан тыш акчалар | 70 | 67 | 74 | 211 |
| | Барлыгы: | 116 | 87 | 96 | 299 |
| шул исәптән төзелешкә, реконструкцияне, техник яңадан җиһазлауны һәм модернизацияләүне кертеп, капитал чыгымлары | Региональ бюджет | 42 | 15 | 17 | 74 |
| | Бюджеттан тыш акчалар | 64 | 59,5 | 64 | 187,5 |
| | Барлыгы: | 106 | 74,5 | 81 | 261,5 |
| шул исәптән җитен җитештерү чыгымнарының бер өлешен субсидияләү | Региональ бюджет | 4 | 5 | 5 | 14 |
| | Бюджеттан тыш акчалар | 6 | 7,5 | 10 | 23,5 |
| | Барлыгы: | 10 | 12,5 | 15 | 37,5 |

## 11. Программаны тормышка ашыруга идарә итү системасына тасвирлама

Программа белән комплекслы идарә итүне һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчалары белән эш итүне бюджетны планлаштыру субъекты - Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы (алга таба – Министрлык) башкара.

Программаны тормышка ашыру белән идарә итү системасы:

программаны тулаем тормышка ашыру, программа максатларына, бурычларына, максат индикаторларына ирешү, программада расланган бурычлар күрсәткечләре һәм гамәлләр өчен Министрлыкның игенчелек тармакларын үстерү бүлеге җаваплы.

Министрлыкның структур бүлекчәләре, Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексының программаны тормышка ашыруда катнаша торган учреждениеләре һәм оешмалары эшчәнлеген координацияләүне һәм аларның программа чараларын тормышка ашыру буенча гамәлләрен килештерүне Министрлыкның икътисадый анализ һәм планлаштыру бүлеге һәм игенчелек тармакларын үстерү бүлеге башкара;

Программаның һәр чарасын һәм, шуннан чыгып, программаны тормышка ашыруны Министрлыкның игенчелек тармакларын үстерү бүлеге һәм кызыксынган бүлекләре башкара;

Программа гамәлләрне финанслауны Министрлыкның финанс бүлеге башкарачак;

Программаның тормышка ашырылуын мониторинглауны Министрлыкның түбәндәге бүлекләре башкарачак: игенчелек тармакларын үстерү бүлеге, икътисадый анализ һәм планлаштыру бүлеге, агросәнәгать комплексын инженер-техник тәэмин итү бүлеге, кадрлар бүлеге, фән, мәгариф һәм инновацион технологияләр бүлеге, азык-төлек базарын үстерү бүлеге, инвестицияләр сәясәте һәм максатчан программалар бүлеге, финанс бүлеге, предприятиеләрне реструктуризацияләү һәм агробизнесны үстерү бүлеге;

Программаны тормышка ашыру барышы турында хисап төзү өчен Министрлыкның игенчелек тармакларын үстерү бүлеге, икътисадый анализ һәм планлаштыру бүлеге, финанс бүлеге, Министрлыкның бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылык бүлеге җаваплы.

Татарстан Республикасы бюджетының программа чараларын тәэмин итүне финанслаудагы чыгым йөкләмәләренең хокукый нигезләре Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы һәм Татарстан Республикасы арасында соңгыларын Программада катнашучылар исәбенә кертү турында килешүләр төзү нәтиҗәсендә барлыкка килә.

## 12. Программаны тормышка ашыруның куркынычлы якларына бәя бирү

Планлаштырылган нәтиҗәләргә ирешүгә йогынты ясарга мөмкин төп куркынычлыкларга түбәндәгеләр керә:

тышкы куркынычлыклар:

дәүләт-хосусый партнерлыгы линиясе буенча инвесторлар ягыннан финанслауның, шулай ук авыл хуҗалыгы җитештерүчеләренең үз акчаларының һәм заем акчаларының җитәрлек дәрәҗәдә булмавы;

табигать-климат шартларының начар булуы;

эчке куркынычлыклар:

җитештерү һәм технология куркынычлыклары;

Программаны тормышка ашыру кысаларында куркынычлыклар белән идарә итү барлык чыганаклардан да үз вакытында кирәгенчә финанслау һәм технологик регламентларны төгәл үтәү рәвешендә башкарылырга тиеш. Энергия чыганакларына, ашламаларга, авыл өчен башка товарларга һәм хезмәт күрсәтүләргә нигезсез югары бәяләргә бәйле булган куркынычлыклар федераль дәрәҗәдә дәүләт тарафыннан идарә ителергә тиеш.

2015 елның 30 сентябрендәге 228-2/пр номерлы
ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы
боерыгына
2 нче кушымта

“2015 – 2016 елларга Татарстан Республикасында җитен комплексын үстерү” ведомство максатчан икътисадый әһәмиятле региональ программасын гамәлгә ашыруда катнашучы авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә, крестьян (фермер) хуҗалыкларына, индивидуаль эшкуарларга 2015 елда субсидияләр бирү тәртибе

1. Әлеге Тәртип “2014 – 2016 елларга Татарстан Республикасында җитен комплексын үстерү” ведомство максатчан икътисадый әһәмиятле региональ программасын (алга таба – Программа) гамәлгә ашыруда катнашучы авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә (алга таба – Программада катнашучылар) 2015 елда субсидияләр бирү механизмын билгели.

2. Субсидияләр әлеге Тәртипнең 4 пунктында каралган максатларга Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы (алга таба – Министрлык) раслаган бюджет йөкләмәләре чигендә бирелә.

3. Субсидияләр бирү шарты булып Программада катнашучыларның төп эшчәнлек юнәлеше авыл хуҗалыгы җитештерүе, җитен җитештерү һәм эшкәртү булу тора.

Субсидияләр бетү стадиясенә күчкән яки бөлгенлекка (банкротлыкка) чыккан дип танылган Программада катнашучыларга бирелми.

4. Субсидияләр бирү максаты җитен җитештерү һәм эшкәртү күләмнәрен арттыру өчен икътисадый һәм технологик шартлар тудыру.

5. Субсидияләр бирү өчен Программада катнашучыларны сайлап алу критериясе җитен җитештерү һәм эшкәртүдән гыйбарәт.

6. Субсидияләр Программада катнашучыларга түбәндәгечә бирелә:

а) җитенне беренчел эшкәртү объектларын төзү, реконструкцияләү һәм модернизацияләү чыгымнарының бер өлешен каплауга – Программа гамәлгә ашырыла башлаганчы бер ел эчендә башкарылган эшләр күләменең 43 проценты исәбеннән, шул исәптән федераль бюджет акчалары хисабына – 20 проценты;

б) җитенне беренчел эшкәртү объектлары өчен технологик җиһазлар, автотранспорт һәм авыл хуҗалыгы техникасын сатып алу чыгымнарының бер өлешен каплауга – Программа гамәлгә ашырыла башлаганчы бер ел эчендә сатып алынган җиһазлар бәясенец 43 проценты исәбеннән, шул исәптән федераль бюджет акчалары хисабына – 20 проценты;

в) җитен җитештерү чыгымнарының бер өлешен каплауга – җитен эшкәртү заводына тапшырылган җитеннең бер мең тоннасына (сүскә күчергәндә) 8600 сум исәбеннән, шул исәптән федераль бюджет акчалары хисабына – 4000 сум.

7. Әлеге Тәртипнең 6 пунктындагы а пунктчасында күрсәтелгән субсидияләрне алу өчен Программада катнашучылар Министрлыкка түбәндәге документларны тапшыралар:

түләү реквизитларын һәм почта адресын күрсәтеп, субсидияләр бирү соралган гаризаны;

төзүгә, реконструкцияләүгә һәм модернизацияләүгә җыелма исәп-хисап сметасының күчермәсен;

төзүгә, реконструкцияләүгә һәм модернизацияләүгә подряд шартнамәсенең күчермәсен;

“Башкарылган эшләрне кабул итү турында акт” КС-2 номерлы статистика формасы буенча белешмәне;

“Башкарылган эшләрнең һәм чыгымнарның бәясе турында белешмә” КС-3 номерлы статистика формасы буенча белешмәне;

эшләрне хуҗалык эшләре ысулы белән башкарганда “Башкарылган эшләрне кабул итү турында акт” КС-2 номерлы статистика формасы һәм “Башкарылган эшләрнең һәм чыгымнарның бәясе турында белешмә” КС-3 номерлы статистика формасы буенча белешмәләрне;

башкарылган эшләр өчен түләүне раслый торган банк тарафыннан таныкланган түләү йөкләмәсен;

Министрлык тарафыннан расланган форма буенча субсидияләр бирү өчен исәп-хисап белешмәләрен.

Тапшырыла торган документларның күчермәләре Программада катнашучылар тарафыннан таныклана.

8. Әлеге Тәртипнең 6 пунктындагы б пунктчасында күрсәтелгән субсидияләрне алу өчен Программада катнашучылар Министрлыкка түбәндәге документларны тапшыралар:

түләү реквизитларын һәм почта адресын күрсәтеп, субсидияләр бирү соралган гаризаны;

җиһазлар һәм техника китерүгә шартнамәне;

товар-транспорт накладнойларын;

ОС-1 формасы буенча җиһазны кабул итү – тапшыру актын;

җиһазлар һәм техника өчен түләүне раслый торган банк тарафыннан расланган түләү йөкләмәләрен;

Министрлык тарафыннан расланган форма буенча субсидияләр бирү өчен исәп-хисап белешмәләрен.

Тапшырыла торган документларның күчермәләре Программада катнашучылар тарафыннан таныклана.

9. Әлеге Тәртипнең 6 пунктындагы в пунктчасында күрсәтелгән субсидияләрне алу өчен Программада катнашучылар Министрлыкка түбәндәге документларны тапшыралар:

түләү реквизитларын һәм почта адресын күрсәтеп, субсидияләр бирү соралган гаризаны;

җитен трестларын китерүгә шартнамәләрне;

товар накладнойлары реестрын;

кабул итү квитанцияләрен;

Министрлык тарафыннан расланган форма буенча субсидияләр бирү өчен исәп-хисап белешмәләрен.

Тапшырыла торган документларның күчермәләре Программада катнашучылар тарафыннан таныклана.

10. Министрлык:

субсидияләр бирү соралган гаризаны кергән көнендә үк журналга терки, ул номерлана, шнурлана һәм аңа Министрлык мөһере сугыла;

гариза теркәлгән көннән алып 20 көн эчендә әлеге Тәртипнең 7, 8 һәм 9 пунктлары нигезендә тапшырылган документларны карый һәм субсидия бирү турында яки субсидия бирүдән баш тарту турында карар кабул итә.

Субсидия бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

Документларның тулы булмаган комплекты тапшырылу яки аларның әлеге Тәртип таләпләренә туры килмәве;

бюджет йөкләмәләре лимитлары калмау.

Субсидияләр бирүдән баш тартылуга шикаять Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә агымдагы ел дәвамында бирелә.

11. Министрлык Программада катнашучылар белән Министрлык тарафыннан расланган форма буенча Субсидия бирү турында килешү төзи.

12. Министрлык бюджет акчаларын баш бүлүче булып тора һәм акчаларны, Министрлык тарафыннан расланган субсидияләр бирү өчен җыелма исәп-хисап белешмәләренә нигезләнеп, үзенең Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсендә яки Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаментында ачылган хосусый счетыннан Программада катнашучыларның исәп-хисап счетларына әлеге Тәртипнең 10 пунктындагы оченче абзацында күрсәтелгән срок беткәннән соң биш көн эчендә күчерә.

13. Алынган субсидияләр, аларны бирүнең әлеге Тәртиптә билгеләнгән максатлары һәм шартлары бозылу, субсидияләрнең максатчан билгеләнеше буенча файдаланылмавы һәм (яки) дөрес булмаган белешмәләр һәм документлар тапшырылу очраклары билгеле булганнан соң, Министрлыкның тиешле таләбен алган көннән башлап 60 көн эчендә федераль бюджет һәм Татарстан Республикасы бюджеты керемнәнә кире кайтарылырга тиеш.

14. Субсидия бирү турында килешүләрдә каралган очракларда, хисап финанс елында файдаланылмый калган субсидияләр хисап елыннан соң килә торган елның 1 февраленә кадәр федераль бюджет һәм Татарстан Республикасы бюджеты керемнәнә субсидияләр алучылар тарафыннан кире кайтарылырга тиеш.

15. Әлеге Тәртипнең 13 һәм 14 пунктларында күрсәтелгән акчаларны федераль бюджет һәм Татарстан Республикасы бюджеты керемнәнә үз ихтыяры белән кайтарудан баш тартылган очракта, алар законнар нигезендә мәҗбүри рәвештә түләттерелергә тиеш.

16. Министрлык һәм (яки) дәүләт финанс контроле органы авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә субсидияләр бирү шартлары, максатлары һәм тәртибе үтәлешен законнарда билгеләнгән тәртиптә тикшерә.

17. Тапшырылган документларның дөреслеге өчен җаваплылык законнар нигезендә Программада катнашучыларның җитәкчеләренә йөкләнә.

18. Бюджет акчаларының максатка ярашлы кулланылышын Министрлык тикшереп тора.

2015 елның 30 сентябрендәге 228-2/пр
номерлы
ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек
министрлыгы боерыгына
3 нче кушымта

“2015 – 2016 елларга Татарстан Республикасында җитен комплексын үстерү” ведомство максатчан икътисадый әһәмиятле региональ программасын гамәлгә ашыруда катнашучы авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә субсидияләр бирү турында

**КИЛЕШҮ №_____**

Казан ш. «____»____________2015

Бер яктан Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы исеменнән, алга таба “Министрлык” дип аталачак, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы мәсьәләләре” 2005 елның 6 июлендәге 316 номерлы карары белән расланган Нигезләмәгә таянып эшли торган Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – министр Әхмәтов Марат Готыф улы һәм икенче яктан

______________________________________________________________

(субсидияләр алучыларның исемнәре, ИНН)

исеменнән, алга таба “Субсидия алучы” дип аталачак, ______________________ нигезендә эшли торган

______________________________________________________________,

(Ф.И.А.и.)

барысы бергә “Яклар” дип йөртеләчәк, “2015 – 2016 елларга Татарстан Республикасында җитен комплексын үстерү” ведомство максатчан икътисадый әһәмиятле региональ программасын гамәлгә ашыруда катнашучы авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә, крестьян (фермер) хуҗалыкларына, индивидуаль эшкуарларга 2015 елда субсидияләр бирү тәртибе нигезендә түбәндәгеләр турында әлеге Килешүне төзеделәр:

## 1. КИЛЕШҮ ПРЕДМЕТЫ

1.1. Министрлык әлеге Килешү һәм Министрлык боерыгы белән расланган “2015 – 2016 елларга Татарстан Республикасында җитен комплексын үстерү” ведомство максатчан икътисадый әһәмиятле региональ программасын гамәлгә ашыруда катнашучы авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә, крестьян (фермер) хуҗалыкларына, индивидуаль эшкуарларга 2015 елда субсидияләр бирү тәртибе нигезендә Субсидия алучыга җитенне беренче тапкыр эшкәртү объектларын төзү, реконструкцияләү һәм модернизацияләү; җитенне беренчел эшкәртү объектлары өчен технологик җиһазлар, автотранспорт һәм авыл хуҗалыгы

техникасын сатып алу; җитен җитештерү чыгымнарының бер өлешен каплауга субсидияләр бирергә йөкләмә ала.

## 1. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

2.1. Субсидияләр бирү “2015 елга, 2016 һәм 2017 еллар план чорына федераль бюджет турында” 2014 елның 1 декабрендәге 384-ФЗ номерлы Федераль законда, “2015 елга, 2016 һәм 2017 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында” 2014 елның 27 ноябрендәге 107-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында каралган бюджет ассигнованиеләре һәм Министрлыкка расланган бюджет йөкләмәләре лимитлары чигендә башкарыла.

2.2. Субсидияләр бирү максатлары җитен җитештерү һәм эшкәртү күләмнәрен арттыру өчен икътисадый һәм технологик шартлар тудырудан гыйбарәт.

## 3. СУБСИДИЯЛӘР БИРҮ ШАРТЛАРЫ

3.1. Субсидияләр алу өчен Субсидия алучы Министрлыкка Тәртипнең 7-9 пунктларында каралган документлар тапшыра.

3.2. Субсидияләр Программада катнашучыларның төп эшчәнлек юнәлеше авыл хуҗалыгы җитештерүе, җитен җитештерү һәм эшкәртү булу шарты үтәлгәндә бирелә.

## 4. ЯКЛАРНЫҢ ХОКУКЛАРЫ ҺӘМ БУРЫЧЛАРЫ

4.1. **Министрлык:**

4.1.1. Әлеге Килешүнең һәм Тәртипнең нигезләмәләрендә каралган очракларда субсидияләр бирүне туктатырга, туктатып торырга яки аларның зурлыгын (күләмен) киметергә (кисәргә) хокуклы.

4.1.2. Җитенне беренче тапкыр эшкәртү объектларын төзү, реконструкцияләү һәм модернизацияләү; җитенне беренчел эшкәртү объектлары өчен технологик җиһазлар, автотранспорт һәм авыл хуҗалыгы техникасын сатып алу; җитен җитештерү чыгымнарының бер өлешен каплауга субсидияләр бирү шартларын үти.

4.1.3. Субсидияләр алучыларның субсидияләр алу өчен кирәкле документларын тикшерергә хокуклы.

4.1.4. Субсидия алучыга Субсидия алучының Килешүдә каралган йөкләмәләрен үтәүгә бәйле мәсьәләләр буенча консультацияләр бирергә.

4.1.5. Субсидияләр биргән вакытта куелган шартлар Субсидия алучы тарафыннан бозылган очракта, алынган субсидияләрне кире кайтаруны таләп итәргә хокуклы.

4.2. **Субсидия алучы түбәндәгеләрне үтәргә йөкләмә ала:**

4.2.1. Иң күбе өч эш көненә тигез срокта язма рәвештә Министрлыкка түбәндәгеләр турында хәбәр итә:

карар кабул ителгән көннән алып бетерелү яки үзгәртеп төзелү турында;

арбитраж суд тарафыннан билгеләмә чыгарылган көннән башлап “Бөлгенлек (банкротлык) турында” 2002 елның 26 октябрендәге 127-ФЗ номерлы Федераль законда каралган банкротлык турындагы эштә күреләә торган процедураларны башлау турында;

карар кабул ителгән көннән соң адрес (урнашу урыны) үзгәрү турында.

4.2.2. Алынган субсидияләрне аларны бирүнең Тәртиптә билгеләнгән максатлары һәм шартлары бозылу, субсидияләрнең максатчан билгеләнеше буенча файдаланылмавы һәм (яки) дөрес булмаган белешмәләр һәм документлар тапшырылу очраклары билгеле булу буенча Министрлыкның тиешле таләбен алган көннән башлап 60 көн эчендә федераль бюджет һәм Татарстан Республикасы бюджеты керемена кире кайтара.

4.2.3. Хисап финанс елында файдаланылмый калган субсидияләрне хисап елыннан соң килә торган елның 1 февраленә кадәр федераль бюджет һәм Татарстан Республикасы бюджеты керемена кире кайтара

4.2.4. Министрлыкка һәм дәүләт финанс (муниципаль) контроле органнарына аларның субсидияләр алучының субсидияләр бирү шартлары, максатлары үтәлешен тикшерүенә ризалык бирә.

## 5. БӘХӘСЛӘРНЕ ХӘЛ ИТҮ

5.1. Килешүнең Яклары Килешү буенча (һәм/яки аңа бәйле рәвештә) барлыкка килә торган бәхәсләрне һәм аңлашылмаучанлыкларны Яклар арасында сөйләшүләр үткәреп хәл итү өчен барлык чараларны да күрәләр.

5.2. Килешүнең Яклары арасында Килешү буенча (һәм/яки аца бәйле рәвештә) барлыкка килү ихтималы булган барлык бәхәсләр һәм аңлашылмаучанлыклар, әгәр алар сөйләшүләр үткәреп хәл ителмәсә, Татарстан Республикасы Арбитраж судында каралырга тиеш.

## 6. ЯКЛАРНЫҢ ҖАВАПЛЫЛЫГЫ

6.1. Яклар әлеге Килешү буенча үз йөкләмәләрен үтәмәгән яки тиешенчә үтәмәгән очракта Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары һәм әлеге Килешү шартлары нигезендә җавап тоталар.

6.2. Субсидия алучы Министрлыкка тапшырыла торган белешмәләрнең дөреслеге, тулылыгы һәм үз вакытында тапшырылыуы һәм Килешүдә билгеләнгән шартларның үтәлеше өчен җаваплы була.

6.3. Субсидия алучы бирелгән субсидияләрне Министрлык таләбе буенча әлеге Килешүнең 4.2.2, 4.2.3. пунктчаларында каралган срокта һәм нигезләр буенча кире кайтармаган очракта, түләү вакыты чыкканнан соңгы һәр календарь көнгә бурыч суммасының 0,5% күләмендә неустойка (пеня) исәпләнә.

## 7. БАШКА ШАРТЛАР

7.1. Әлеге Килешүгә барлык үзгәрешләр, өстәмәләр, әгәр алар язма рәвештә башкарылган һәм ике Якның да моңа вәкаләтләре булган вәкилләре тарафыннан имзаланган булсалар, дөрес булалар һәм аның аерылгысыз өлешләре булып торалар.

7.2. Әлеге Килешү ике нөсхәдә төзелде, алар бертигез юридик көчкә ия.

7.3. Әлеге Килешү ике Якның да кул куярга вәкаләтләре булган вәкилләре тарафыннан имзаланган вакыттан алып 2015 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

## 8. ЯКЛАРНЫҢ ЮРИДИК АДРЕСЛАРЫ ҺӘМ ТҮЛӘҮ РЕКВИЗИТЛАРЫ

Министрлык:
Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы
һәм азык-төлек министрлыгы
420014, Татарстан Республикасы,
Казан ш., Федосеевская ур., 36 нчы й.
р/с 40101810800000010001
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИЛЛИ
БАНКЫНЫҢ КАЗАН ШӘҺӘРЕ БҮЛЕГЕ
Татарстан Республикасы буенча УФК
(Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы
һәм азык-төлек министрлыгы,
04112001090)
ИНН 1654019555
КПП 165501001
ОГРН 1021602854580

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
урынбасары – министр
______________________М.Г. Әхмәтов

Субсидия алучы:

Җитәкче
________________Ф.И.А.и.

2015 елның 30 сентябрендәге 228-2/пр номерлы
ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы боерыгына
4 нче кушымта

Форма

**“2015 – 2016 елларга Татарстан Республикасында җитен комплексын үстерү ” ведомство максатчан икътисадый әһәмиятле региональ программасын гамәлгә ашыруда катнашучы авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә, крестьян (фермер) хуҗалыкларына, индивидуаль эшкуарларга федераль бюджет акчалары исәбеннән бирелергә тиешле субсидияләр турында исәп-хисап белешмә**

___________________________________________________буенча

(субсидия алучының исеме, муниципаль районның исеме)

| Программаны гамәлгә ашыра башлаудан алып тотылган чыгымнарның күләме | Чыгымнар суммасы, сум | Субсидия ставкасы | Субсидия суммасы, сум |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| Җитенне беренчел эшкәртү объектларын төзү | | чыгымнар күләменнән 20% | |
| Җитенне беренчел эшкәртү объектлары өчен технологик җиһазлар, автотранспорт һәм авыл хуҗалыгы техникасын сатып алу | | чыгымнар күләменнән 20% | |
| Барлыгы: | | X | |
| Продукциянең исеме | Җитештерү күләме, тонна | Субсидия ставкасы (сум) | Субсидия суммасы, сум |
| Җитен тресты (сүскә күчергәндә) | | 4000 | |
| Барлыгы: | X | X | |

Белешмәләрнең дөреслеген раслыйм:
Субсидия алучы оешманың җитәкчесе (имза) ФИАи

Баш бухгалтер ____________________ ____________________
(булган очракта мөһер) (имза) ФИАи

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Татарстан Республикасы __________________ муниципаль районында
Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы ____________________ ________________
(имза) ФИАи

Баш бухгалтер
(мөһер) _____________ ____________________

ТР Премьер-министры урынбасары – (имза) ФИАи
ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры
(мөһер)
_______________________М.Г.Әхмәтов
(имза)

2015 елның 30 сентябрендәге 228-2/пр номерлы
ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы боерыгына
5 нче кушымта

Форма

“2015 – 2016 елларга Татарстан Республикасында җитен комплексын үстерү ” ведомство максатчан икътисадый әһәмиятле региональ программасын гамәлгә ашыруда катнашучы авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә, крестьян (фермер) хуҗалыкларына, индивидуаль эшкуарларга Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән бирелергә тиешле субсидияләр турында исәп-хисап белешмә

________________________________________________________буенча

(субсидия алучының исеме, муниципаль районның исеме)

| Программаны гамәлгә ашыра башлаудан алып тотылган чыгымнарның күләме | Чыгымнар суммасы, сум | Субсидия ставкасы | Субсидия суммасы, сум |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| Җитенне беренчел эшкәртү объектларын төзү | | чыгымнар күләменнән 23% | |
| Җитенне беренчел эшкәртү объектлары өчен технологик җиһазлар, автотранспорт һәм авыл хуҗалыгы техникасын сатып алу | | чыгымнар күләменнән 23% | |
| Барлыгы: | | Х | |
| Продукциянең исеме | Җитештерү күләме, тонна | Субсидия ставкасы (сум) | Субсидия суммасы, сум |
| Җитен тресты (сүскә күчергәндә) | | 4600 | |
| Барлыгы: | Х | Х | |

Белешмәләрнең дөреслеген раслыйм:
Субсидия алучы оешманың җитәкчесе (имза) ФИАи

Баш бухгалтер ____________________ ________________
(булган очракта мөһер) (имза) ФИАи

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Татарстан Республикасы _________________ муниципаль районында
Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы ____________________ ________________
(имза) ФИАи

Баш бухгалтер
(мөһер) ____________ ____________________

ТР Премьер-министры урынбасары – ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры (имза) ФИАи
(мөһер)

______________________М.Г.Әхмәтов
(имза)